**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чемодурово авыл җирлеге Советы карары**

Чемодурово авылы №96 "18 " июнь 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының 18.06.2018 №96 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итүне тәэмин итү нигезләмәсенә үзгәреш кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 27 июлендәге 227-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Чемодурово авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы авыл җирлеге Советының 18.06.2018 №96 карары белән расланган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлегендә гражданнарның мөрәҗәгатьләрен карау һәм гражданнарны шәхсән кабул итүне тәэмин итү нигезләмәсенә үзгәреш кертергә, 2.10 пунктындагы "б" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итеп:

«б) мөрәҗәгать итүне карау өчен кирәкле документларны һәм материалларны судлардан, сорау алу органнарыннан һәм алдан тикшерү органнарыннан тыш, башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм башка вазыйфаи затлардан соратып алалар, шул исәптән электрон рәвештә;».

2. Әлеге карарны веб-адрес буенча «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталы»нда урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo. tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында веб-адрес буенча урнаштырырга: http//aznakayevo. tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Рәис Н.Б.Котельникова